КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 6 декабрь г.Казань № 1112

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда инвалидлар өчен капиталь төзелеш объектларыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тотуны оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2018 ел, 1 сентябрь, 745 нче карары белән расланган Төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда инвалидлар өчен капиталь төзелеш объектларыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тотуны оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда инвалидлар өчен капиталь төзелеш объектларыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тотуны оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2018 ел, 1 сентябрь, 745 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 4 октябрь, 903 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда инвалидлар өчен капиталь төзелеш объектларыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тотуны оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктның икенче һәм өченче абзацларында «(дәүләт яки дәүләткә карамаган экспертиза)» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Инвалидлар өчен капиталь төзелеш объектларыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тоту предметы – капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү барышында эшләр башкаруның һәм кулланыла торган төзелеш материалларының, шулай ук мондый эшләр нәтиҗәләренең Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясындагы 15, $15^2$ һәм $15^3$ өлешләре нигезендә расланган проект документлары (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.8 һәм 3.9 өлешләре нигезендә проект документларына кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) һәм (яки) мәгълүмат моделе (мәгълүмат моделен формалаштыру һәм алып бару Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы таләпләре нигезендә мәҗбүри булып торса) таләпләренә туры килү-килмәвен тикшерү.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин